**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорына керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр бирү турында**

Россия Федерациясе Президентының «2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорына керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр бирү турында» 2020 елның 17 апрелендәге 272 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм:**

1. Аларны бирү вакыты Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указында һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында» 2010 елның 11 гыйнварындагы ПУ-4 номерлы Указында каралган 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорына керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр 2020 елның 1 августына кадәр (1 августны кертеп) бирелә дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре җитәкчеләренең 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорына керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү вакытын 2020 елның 1 августына кадәр (1 августны кертеп) озайтырга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә:

муниципаль вазыйфалар биләүче затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә алар тарафыннан 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорына керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти

характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр биргәндә әлеге Указга таянырга;

муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорына керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү вакытын 2020 елның 1 августына кадәр (1 августны кертеп) озайтырга.

4. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 24 апрель
№ ПУ-250